СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» март 2023 ел № 69

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Пыжмара авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнардан сораштыру үткәрүне билгеләү һәм тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 20.07.2020 № 236-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмара авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Пыжмара авыл җирлегенең 2012 елның 14 ноябрендә 58 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнардан сораштыру үткәрүне билгеләү һәм тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.7 пунктында:

1 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Гражданнарны сораштыру үткәрү өчен муниципаль берәмлекнең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтын кулланылырга мөмкин. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының гражданнардан сораштыру билгеләү турындагы карарында түбәндәгеләр билгеләнә:»;

- түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы пункт белән тулыландырырга:

"6) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтын кулланып, гражданнардан сораштыру үткәргән очракта сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.»;

1.2. 17.1 пунктның 2 абзацын "муниципаль берәмлектә яшәүчеләрне" дигән сүзләр белән тулыландырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы Р.Х.Җәләев